| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ** |
| **ПРИКАЗ**<br>23.08.2022 | Казан ш. | **БОЕРЫК**<br>731-п |

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 17 ноябрендәге 1251-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча административ регламентына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 17 ноябрендәге 1251-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча административ регламентына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бирергә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
2021 елның 17 ноябрендәге
1251-п номерлы (2022 елның
23 августындагы 731-п
номерлы боерыгы
редакциясендә) боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып су алу корылмаларының милекчесе булган юридик һәм физик затлар, су алу корылмаларыннан файдаланучы юридик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче) тора.

Мөрәҗәгать итүченең вәкиле булып тиешле вәкаләтләрнең үзенә бирелүен раслый торган, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән документлар нигезендә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат эш итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык)

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ) дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) Норматив-хокукый характердагы боерык рәвешендә рәсмиләштерелгән эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын (алга таба – ССЗ) билгеләү турында карар;

2) Норматив-хокукый характердагы боерык рәвешендә рәсмиләштерелгән эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын үзгәртү турында карар;

3) Норматив хокукый характердагы боерык рәвешендә рәсмиләштерелгән эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналары аларның гамәлдә булуын туктату турында карар;

4) Эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклау зоналарын билгеләүдән, үзгәртүдән, гамәлдә булуын туктатудан баш тарту турында карар (алга таба – баш тарту турында карар).

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында – гаризада күрсәтелгән электрон почта адресына, мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы (алга таба – Республика порталы) (https://uslugi.tatarstan.ru/) шәхси кабинетына;

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе нинди дә булса дәүләт мәгълүмат системасында теркәлми.

2.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе гамәлдә булган чор дәвамында электрон документ яки кәгазьдәге электрон документ нөсхәсе рәвешендә алырга хокуклы.

2.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы гариза һәм аңа беркетелгән документлар теркәлгәннән соң 24 эш көне тәшкил итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытына (24 эш көне) эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар-саклык зоналарын

билгеләү, үзгәртү, туктату турында норматив хокукый характердагы боерык рәвешендә рәсмиләштерелгән карарны дәүләт теркәвенә алу срогы кертелми.

Эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турындагы карар мөрәҗәгать итүчегә норматив хокукый характердагы боерык үз көченә кергән көннән алып 3 эш көне эчендә бирелә (җибәрелә).

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге, дәүләт хезмәтен күрсәтә торган Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан хезмәткәрләре, хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында урнаштырылган.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү һәм эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын үзгәртү турында карар кабул итү өчен мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) түбәндәгеләрне тапшыра (җибәрә):

1) Регламентка 1 нче кушымта нигезендә форма буенча эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш суы чыганакларының ССЗ билгеләү яки үзгәртү турында гариза;

2) законнар һәм СанПиН 2.1.4.110-02 таләпләренә туры китереп эшләнгән эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проекты, кәгазьдә һәм электрон рәвештә;

3) СанПиН 2.1.4.1110-02 таләпләренә туры китереп, су объектын санитар саклау зоналары чикләрен китереп, картографик материал (санитар саклык зонасы проекты составында):

- санитар саклык зонасының 1:500 - 1:1000 зурлыгындагы беренче пояс планы;

- санитар саклык зонасының 1:10000 - 1:25000 зурлыгындагы икенче һәм өченче пояс планы – җир асты су чыганагында һәм 1:25000 - 1:50000 зурлыгында – өске сулык чыганагында, әлеге территориядә урнашкан барлык объектлар төшереп;

4) Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Торак пунктлар, территориаль зоналар, махсус сакланыла торган табигать территорияләре, территориясеннән файдалануда махсус шартлары булган зоналар чикләре урнашкан урынны график яктан тасвирлау формасын, торак пунктлары, территориаль зоналар, махсус сакланыла торган табигать территорияләре, территориясеннән файдалануда махсус шартлары булган зоналар чикләре урнашкан урынны текст белән тасвирлау формасын, торак пунктлары, территориаль зоналар, махсус сакланыла торган табигать территорияләре, территориясеннән файдалануда махсус шартлары булган зоналар чикләренең

характерлы нокталары координадаталырн билгеләү төгәллегенә, торак пунктлары, территориаль зоналар, махсус сакла磁ныла торган табигать территорияләре, территориясеннән файдалануда махсус шартлары булган зоналар чикләре турында белешмәләрне үз эченә алган электрон документ форматына карата таләпләр билгеләү турында һәм Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2016 елның 23 мартындагы 163 номерлы һәм 2018 елның 4 маендагы 236 номерлы боерыкларын көчен югалткан дип тану турында» 2018 елның 23 ноябрендәге 650 номерлы боерыгы (алга таба – 650 номерлы боерык) нигезендә су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зоналары проектында билгеләнгән су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасы чикләре турында электрон формадагы белешмәләр (чикләрнең урнашу урынына текстлы һәм график тасвирлама, координаталар системасында Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен билгеләнгән әлеге чикләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге).

Су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зоналары чикләре турындагы белешмәләрне, су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зоналары чикләренең урнашкан урынын текст һәм графика белән тасвирлаган эчтәлекне үз эченә алган электрон документ форматы, координаталар системасы, су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталарын билгеләү төгәллеге «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә, законга кагылышлы Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актларына, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең норматив хокукый актларына туры килергә тиеш;

5) 650 номерлы боерык нигезендә рәсмиләштерелгән һәм кадастр инженеры тарафыннан имзаланган XML-файл форматында электрон рәвештәге характерлы нокталарның координаталары исемлеге;

2.6.2. Эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналары аларның гамәлдә булуын туктату турында карар кабул итү өчен гариза белән бергә түбәндәгеләр тапшырыла:

- санитар саклык зонасы аларның гамәлдә булуын туктату нигезләре;

- санитар саклык зонасын урнаштыруга бәйле рәвештә су алу корылмасын эксплуатацияләүне туктатуны раслаучы документларның күчермәләре.

2.6.3. Ышаныч кәгазе буенча гаризаны рәсмиләштергәндә вәкаләтле зат тарафыннан паспорт (шәхесне раслаучы башка документ), законнар нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

2.6.4. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

1) Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, Регламентның 2.6.4 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла);

2) шәхсән яисә ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан кәгазь чыганактагы документ формасында;

3) кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән.

2.6.5. Гаризаны һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргән очракта, физик затлар һшм шәхси эшкуарлар гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имза алу өчен мөрәҗәгать итүчегә электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик багланышларын тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба – БИАС) теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын да расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затларның вәкилләре гаризаны һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргән очракта, гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

Мөрәҗәгать итүче вәкиленең электрон документ рәвешендәге (электрон документ үрнәге) ышаныч кәгазе мондый документларны ясауга һәм имзалауга вәкаләтле булган затларның, шул исәптән нотариусның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән таныклана.

Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклау шәхси кабул итү вакытында Россия Федерациясе гражданины паспортын яисә, Россия Федерациясе законнары нигезендә яки «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы федераль законның 14.1 статьясының 18 өлешендә каралган мәгълүмат технологияләрен кулланып, идентификация һәм аутентификация ярдәмендә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Кәгазьдә бирелгән гариза мөрәҗәгать итүченең мөһере (булган очракта) (юридик зат өчен) беркетелергә һәм мөрәҗәгать итүче яисә мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле җитәкчесе тарафыннан имзаланган булырга тиеш. Кәгазьдә бирелгән барлык кәгазь битләре дә тегелгән һәм номерланган булырга тиеш.

Гаризага теркәлеп бирелә торган электрон документлар (документларның электрон рәвешләре), шул исәптән ышаныч кәгазьләре 50 Мбайттан артмаган үлчәмдә pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматларындагы файллар рәвешендә җибәрелә.

Электрон документларның (электрон документ рәвешләренең) сыйфаты документ текстын тулы күләмдә уку һәм документ реквизитларын тану мөмкинлеген бирергә тиеш.

Дәүләт серенә караган белешмәләр булган материаллар дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп тапшырыла.

2.6.6. Вәкаләтле органнардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:

ССЗ проектының санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмәнең күчермәсе яисә ССЗ чикләренең һәм мондый зоналар чикләрендәге җир кишәрлекләренең санитария кагыйдәләренә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмәнең күчермәсе.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге.

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

- Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүе.

- электрон формадагы гариза һәм документлар 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләрен бозып, электрон имза белән имзаланган очракта;

- гаризада һәм аңа теркәп тапшырыла торган документларда билгеләнгән тәртиптә расланмаган чистарту, өстәп язу урыннары һәм төзәтмәләр булуы.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Регламентка 2 нче кушымтада билгеләнгән формага туры китереп рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетка җибәрелә.

2.7.3. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Республика порталында, Министрлыкның рәсми сайтында басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге.

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.8.2. Эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш суы чыганакларының ССЗ билгеләү, үзгәртү турында карар кабул итүдән баш тарту нигезләре:

1) гаризада түбәндәгеләр күрсәтелмәсә яки дөрес күрсәтелмәгән булса:

- мөрәҗәгать итүче турында белешмәләр: оештыру-хокук формасы, юридик һәм почта адресы, элемтә өчен телефоннар күрсәтелгән оешманың тулы һәм кыскартылган исеме;

- файдалану шартларын тәэмин итүгә бәйле рәвештә санитар саклык зонасы билгеләнә торган су алу җайланмасының атамасы, су алу җайланмасының географик координатлары;

2) әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы яисә тулы күләмдә тапшырылмавы;

3) санитар саклык зонасы проектында билгеләнгән су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасы чикләре турындагы белешмәләрнең су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасы чикләре турындагы белешмәләр, су белән тәэмин итү чыганагы санитар саклык зонасы чикләренең урнашу

урынының текст һәм график тасвирламасы булган электрон документта бирелгән белешмәләргә туры килмәве;

4) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә булган җавапларда эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар-саклык зоналары чикләрен билгеләүгә, үзгәртүгә, аларның гамәлдә булуын туктатуга комачаулык итүче мәгълүматлар булуы;

5) су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасы чикләре турында белешмәләрдә мондый зона чикләренең урнашу урынының текст һәм график тасвирламасы булмавы;

6) санитар-саклык зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан күчемсез милекнең дәүләт кадастрын алып бару өчен билгеләнгән координаталар системасында булмавы.

2.8.3. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Республика порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре.

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артык булырга тиеш түгел.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Гаризаны Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза теркәлгән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

2.11.2. Министрлыкка шәхси мөрәҗәгать иткәндә гаризаны теркәү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Гариза алынган көннән соң бер көн эчендә теркәлә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм

Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр.

Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән Министрлык биналарында һәм бүлмәләрендә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

Министрлык территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү;

хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

Гамәлдәге социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларын инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып тулысынча яраклаштырып булмаса, аларны реконструкцияләгәнчегә һәм капиталь ремонтлаганчыга кадәр, Министрлык Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренең берсе белән килештереп, мумөикн булган очракта, инвалидларның хезмәт күрсәтү урынына керүен тәэмин итү өчен чаралар күрергә яисә кирәкле хезмәтләрне инвалидның яшәү урыны буенча яисә дистанцион режимда күрсәтүне тәэмин итәргә тиеш.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу

күрсәткечләре

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан Регламент бозылу очракларына карата нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Министрлык бүлмәләренең җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;

мәгълүмат стендларында, Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булуы.

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүгә комачаулаган каршылыкларны бетерүдә ярдәм итү;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуы, инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүгә комачаулый торган башка каршылыкларны бетерүдә ярдәм күрсәтү;

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Республика порталында шәхси кабинеттан, Министрлыкта алынырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм башка документлар турындагы белешмәләрдән файдалану мөмкинлеге, алдан авторизация узмыйча гына, Порталдагы «шәхси кабинет» аша гамәлгә ашырыла.

«Шәхси кабинет»та авторизацияләнгәннән соң, мөрәҗәгать итүче Республика порталы аша түбәндәге мөмкинлекләрне ала:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны бирергә;

кирәк булганда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон үрнәкләрен (график файлларны) беркетергә;

дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алырга;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алырга.

Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны электрон рәвештә бирү мөмкинлеген тәэмин итү өчен, мөрәҗәгать итүчедә гади электрон имза ачкычы булырга тиеш. Гади электрон имза ачкычын (алга таба – гади электрон имза) алу өчен мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү процедурасын узарга кирәк. ИАБС системасында алдан теркәлүнең онлайн-формасы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтта

урнаштырылган («Интернет» челтәрендәге сайтның домен исеме – esia.gosuslugi.ru/).

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.

2.14.2. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Республика порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон белдерү формасында алырга;

е) дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган Республикасы порталы ярдәмендә Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.3. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчедән, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан тыш, бүтән гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

2.14.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) гариза һәм документларны кабул итү, теркәү;

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны карау, эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зонасын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карар яки санитар саклык зонасын билгеләүдән, үзгәртүдән, аларның гамәлдә булуын туктатудан баш тарту турында карар әзерләү һәм кабул итү;

5) эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зонасын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында норматив хокукый характердагы боерык рәвешендә рәсмиләштерелгән карарны дәүләт теркәвенә җибәрү;

6) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

7) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен зарури документларны (аларда булган белешмәләрне) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибендә җибәрү;

8) техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүе административ процедураны башкару өчен нигез булып тора.

Мөрәҗәгать итүче Бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яки) почта аша (шул исәптән электрон) мөрәҗәгать итәргә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Республика порталында консультация алырга хокуклы.

Телдән мөрәҗәгать иткән очракта, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гариза формасы һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләр буенча. Кирәк булганда Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә.

Әгәр гражданин мөрәҗәгатенә язмача җавап алырга тели икән, Министрлык мөрәҗәгать итүчене язмача консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карау.

3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны Республика порталы аша электрон формада кабул итү.

Республика порталы аша электрон формада гариза тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Республика порталында авторизацияләнә;

Республика порталында гаризаның электрон формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза Регламентның 2.6.4 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: электрон багланышлар системасы аша Министрлыкка җибәрелгән электрон эш.

3.3.1.1. Министрлык тарафыннан документлар комплектын карау.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларның Республика порталыннан алынуы административ процедура үтәлешен башлау нигезе булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) - Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге белгече (алга таба – контрольлек бүлеге белгече).

Документлар карап тикшерүгә кергәннән соң контрольлек бүлеге белгече:

гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм «Документларны тикшерү» статусын беркетә, ул Республика порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла;

алынган электрон эшләрне, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон формада теркәлгән документларны һәм документларның электрон үрнәкләрен өйрәнә;

документларның электрон үрнәкләренең комплектлылыгын, укылышлы булуын тикшерә;

Республика порталына юлы белән, электрон имзаның чын булу шартлары үтәлешен тикшерә (әгәр мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон үрнәкләре тапшырылган булса).

Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты әзерли.

Баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, документларны кабул итүдән баш тарту турында карар (дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр Регламентка 2 нче кушымтадагы форма буенча рәсмиләштерелсә) Электрон документ әйләнеше системасында теркәлә һәм Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзалана һәм Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына гариза алынган көннән башлап бер эш көненнән соңга калмыйча җибәрелә.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның чын булу шартларының үтәлмәве ачыкланса, баш тарту турындагы карар проектында аны кабул итү өчен нигез булган 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясындагы пунктлары булырга тиеш.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат гариза алынган көннән соң бер эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә гаризаның алынуы турында теркәү номеры, гаризаны алу датасы, үзенә килгән документларның файллары атамалары исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу датасы күрсәтелгән белдерү җибәрә.

3.3.1.2. Регламентның 3.3.3.1 пунктында күрсәтелгән процедуралар үтәлеше, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза килгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: карап тикшерүгә кабул ителгән документлар комплекты яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты.

3.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) шәхсән кәгазь чыганакта, кулга тапшыру турында

белдереп, заказлы почта юлламасы итеп, «Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы (алга таба – Электрон документ әйләнеше) аша электрон рәвештә кабул итү.

3.3.2.1. Мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны кушып, Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлегенә гариза бирә (җибәрә).

Регламентның әлеге пунктында билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче гаризаны Министрлыкка биргән очракта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән гариза.

3.3.2.2. Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге белгече:

гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кабул итә һәм терки.

гаризаны гаризаларны теркәү журналында терки (электрон рәвештә);

мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) документларны кабул итү көне, ае, елы, беркетелгән кереш номеры турында тамга куеп, гариза күчермәсен тапшыра;

Каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге (алга таба – Бүлек) җитәкчесенә гариза һәм документларның карап тикшерүгә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән, Бүлек җитәкчесенә тапшырылган документлар.

3.4. Административ процедураны башлап җибәрү өчен теркәү турында тамгалап, Бүлеккә документларның һәм материалларның алынуы тора.

Бүлек җитәкчесе гаризаны һәм материалларны карау өчен җаваплы башкаручы (алга таба – Бүлек белгече) билгели һәм тиешле карар кабул итү өчен тапшырылган материалларны аңа тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза алынган көнне башкарыла.

3.5. Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә санитар саклык зонасы проектының санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә күчермәсен яки санитар саклык зонасы чикләренең һәм мондый зоналарда җир кишәрлекләреннән файдаланудагы чикләүләрнең санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә күчермәсен бирү турында электрон формада рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә (Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсенә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр (документлар) бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.6. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (белешмәне) бирә яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен

кирәкле документның һәм (яисә) белешмәләрнең булмавы турында хәбәр (алга таба – документның һәм (яисә) белешмәләрнең булмавы турында хәбәр) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, законнарда билгеләнгән срокларда җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә мәгълүмат белән тәэмин итүче зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яки баш тарту турында белдерү.

3.7. Документларны карау, эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зонасын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карар яки санитар саклык зонасын билгеләүдән, үзгәртүдән, аларның гамәлдә булуын туктатудан баш тарту турында карар әзерләү һәм кабул итү.

3.7.1. Бүлек белгече Регламентның 3.5 һәм 3.6 пунктлары нигезендә соратып алынган белешмәләр (документлар) алынганнан соң эчәргә яраклы һәм хуҗалык-эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зонасы чикләрен билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Эчәргә яраклы һәм хуҗалык-эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зонасы чикләрен билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карар кабул итүдән (дәүләт хезмәте күрсәтүдән) баш тарту өчен Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, Бүлек белгече баш тарту турында карар проектын әзерли.

Баш тарту өчен нигезләр булмаса, Бүлек белгече эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зонасы чикләрен билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында норматив хокукый характердагы боерык проекты рәвешендә рәсмиләштерелгән карар проектын әзерли.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатькә җавап алынганнан соң алты эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зонасы чикләрен билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында норматив-хокукый характердагы боерык проекты (алга таба – боерык проекты) рәвешендә рәсмиләштерелгән карар проекты яки эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зонасы чикләрен билгеләүдән баш тарту турында карар проекты (алга таба – Карар).

3.7.2. Бүлек җитәкчесе боерык проектын яки баш тарту турында карар проектын карый, килештерә һәм килештерү өчен Минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе җитәкчесенә (алга таба – Идарә) җибәрә.

3.7.3. Идарә җитәкчесе боерык проектын яки баш тарту турында карар проектын карый, килештерә һәм Бүлек белгеченә җибәрә.

3.7.2, 3.7.3 пунктчаларда билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек җитәкчесе һәм Идарә җитәкчесе

тарафыннан килештерелгән, Бүлек белгеченә җибәрелгән санитар саклык зонасын билгеләү турында боерык проекты яки баш тарту турында карар проекты.

3.7.4. Бүлек белгече Бүлек җитәкчесе һәм Идарә җитәкчесе килештергән боерык проектын яки баш тарту турындагы карар проектын хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек җитәкчесе һәм Идарә җитәкчесе тарафыннан килештерелгән, хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесенә җибәрелгән боерык проекты.

3.7.5. Хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесе проектка хокукый экспертиза үткәрә, боерык проектын яки баш тарту турындагы карар проектын килештерә һәм Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек җитәкчесе, Идарә җитәкчесе, хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесе тарафыннан килештерелгән боерык проекты яки баш тарту турындагы карар проекты.

3.7.6. Бүлек белгече Бүлек җитәкчесе, Идарә җитәкчесе, хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесе тарафыннан килештерелгән боерык проектын яки баш тарту турындагы карар проектын имзалау өчен министрның җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләрен алып баручы урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек җитәкчесе, Идарә җитәкчесе, хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесе тарафыннан килештерелгән боерык проекты яки баш тарту турында Бүлек җитәкчесе, Идарә җитәкчесе тарафыннан килештерелгән карар, җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләрен алып баручы министр урынбасарына юлланган.

3.7.7. Җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләрен алып баручы министр урынбасары боерык проектын яки баш тарту турында карар проектын карый һәм килештерә һәм Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрга кул кую өчен җибәрелгән, килештерелгән боерык проекты яки баш тарту турында карар проекты.

3.7.8. Министр норматив хокукый характердагы боерык проектын яисә баш тарту турындагы карарны имзалый, алар документларны үтәүне контрольдә тоту бүлегенә теркәү өчен җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кул куелган һәм Министрлыкта теркәлгән, норматив хокукый характердагы боерык рәвешендә рәсмиләштерелгән карар яисә баш тарту турында карар.

3.8. Норматив хокукый характердагы боерык республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләре нигезендә дәүләт теркәвенә җибәрелә, алар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2002 елның 18 июлендәге 426 номерлы карары белән расланган.

3.9. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.9.1. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламентның 3.7.8 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән Баш тарту турында карар җибәрә.

Язмача формада мөрәҗәгать итүчегә турыдан-туры Министрлыкта яки почта аша юллап, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында һәм (яки) Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) баш тарту турында белдерү.

3.9.2. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт теркәвенә алынган норматив-хокукый характердагы боерыкны тапшыру.

Норматив хокукый характердагы, дәүләт теркәвенә алынган боерык мөрәҗәгать итүчегә Бүлек белгече тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән җибәрелә.

Язмача формада мөрәҗәгать итүчегә турыдан-туры Министрлыкта яки почта аша юллап, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында һәм (яки) Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар норматив-хокукый характердагы боерык үз көченә кергән көннән өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән), дәүләт теркәве үткән норматив-хокукый характердагы боерык.

3.10. Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен зарури документларны (аларда булган белешмәләрне) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибендә җибәрү.

Министрлык норматив хокукый характердагы боерык үз көченә кергән көннән башлап биш эш көне эчендә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан дәүләт кадастар исәбенә алуны, хокукларны дәүләт теркәвенә алуны, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып баруны һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләрне бирүне гамәлгә ашыру өчен вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органына (аның территориаль органына) (алга таба – хокукларны теркәү органы) су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зонасын билгеләү, үзгәртү яки аларның гамәлдә булуын туктату турындагы белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен кирәкле документларны (аларда булган белешмәләрне), шул исәптән әлеге Регламентның 2.6 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүче тапшырган документларны да тапшыра (җибәрә).

Хокукларны теркәү органына җибәрелә (тапшырыла) торган документларның исемлеге һәм аларда булган белешмәләрнең составы, аларны, шул исәптән электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган электрон хезмәттәшлекнең төбәктәге ведомствоара системаларыннан файдаланып, җибәрү (тапшыру) тәртибе, мондый документларның электрон формадагы форматы «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә, законга кагылышлы Россия Федерациясе норматив хокукый актларына, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының норматив хокукый актларына туры килергә тиеш.

3.11. Техник хаталарны төзәтү.

3.11.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата) ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (Регламентка 3 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документ;

техник хатасы (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны (язу, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан Министрлыкка шәхсән тапшырыла яисә почта буенча (шул исәптән электрон почта ярдәмендә дә), Республика порталы аша җибәрелә.

3.11.2. Министрлыкның документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлеге белгече техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, кушымта итеп бирелгән документлары белән гаризаны терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.11.3. Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында әлеге Регламентның 3.10.2 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) булган документның төп нөсхәсен алып калып тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта (электрон почта) аша Бүлеккә техник хатасы (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) булган документның төп нөсхәсен тапшырган очракта документ алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата (язу, басма хатасы,

грамматик яки арифметик хата) ачыкланганнан соң яки мәнфәгатьле теләсә кайсы заттан җибәрелгән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата) турында гариза алынган вакыттан башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануны даими рәвештә тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган идарәләрнең (бүлекләрнең) җитәкчеләре тарафыннан Регламент нигезләмәләренең үтәлүенә һәм башкарылуына тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.3. Агымдагы контрольлек Министрлыктагы вазыйфаи затларның Регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләргә тикшерүләр үткәрүне, карарлар кабул итүне, җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнардагы (Регламенттагы) таләпләргә туры килү-килмәвенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.5. Административ регламент үтәлешенә планнан тыш тикшерү уздыру турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, әлеге административ регламентны үтәү өчен җаваплы булып, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлык эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәре карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен, 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, Регламентта каралмаган документлар тапшыру таләп ителгәндә;

4) хезмәт күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, Регламентта каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән бүтән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында, Регламентта нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен

күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, Регламентта каралмаган түләү кертү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, аның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматны таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://eco.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (https://uslugi.tatarstan.ru) файдаланып җибәрелә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында кабул итеп алына ала.

5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш. Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы 5 эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы

вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаятьне канәгатьләндерү турында, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән, дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка формаларда да;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы икенче көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Министрлыкта гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.10. Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

Татарстан Республикасы экология һәм
табигать ресурслары министрына
_______________________________________________
кемнән: ____________________________________
(физик затлар, шәхси эшкуарлар өчен):
(Фамилия, исем, ата исеме
(соңгысы – булган очракта);
урнашу урыны адресы:
_______________________________________________
_______________________________________________
юридик затның адресы һәм (яки) электрон адресы;
_______________________________________________
_______________________________________________
(юридик затлар өчен: оешманың тулы һәм кыскартылган атамасы, оештыру-хокукый рәвешен күрсәтеп)
ИНН, ОГРН белешмәләре _____________________
урнашу урыны _______________________________
элемтә телефоны _____________________________
юридик зат адресы____________________________

Эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында гариза

Сездән эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында үтенәм (кирәклесе астына сызарга) ___________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(су алу корылмасының исеме, аның урнашу урыны)
Эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган су объектының атамасы:___________________________________________________________
Судан файдалану урынының географик координаталары (скважиналар, өслектән су алу урыннары) ___________________________________________________________________
Су объектыннан файдалану хокукын раслаучы документ реквизитлары:
- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия (җир астыннан су алу өчен) _____
______________________________________________________________________________
лицензиянең теркәлү номеры, бирелгән датасы, гамәлдә булу вакыты

- судан файдалану килешүе (өслектән су алу өчен) ____________________
_______________________________________________________________________________;

судан файдалану килешүенең номеры, теркәлү номеры, бирелгән датасы, килешүнең гамәлдә булу вакыты

- Санитар саклык зонасы проекты буенча Роспотребнадзор идарәсе бәяләмәсе реквизитлары
_______________________________________________________________________________;

санитар саклык зонасы чикләренең һәм мондый зоналар чикләрендә җир кишәрлекләреннән файдаланудагы чикләүләрнең санитар кагыйдәләргә туры килүе турында Роспотребнадзор идарәсе бәяләмәсенең теркәлү номеры, бирелгән көне, гамәлдә булу вакыты яки реквизитлары ____________________________________________________________;

теркәлү номеры, бирелгән датасы, гамәлдә булу вакыты

- Беренче санитар саклык зонасы поясы астында кадастр кишәрлегенең номеры______________.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь чыганак булган документ рәвешендә бирүегезне үтенәм:

а) шәхсән тапшырырга;

б) урнашу урыны буенча кәгазь документ формасында җибәрергә
(кирәклесе астына сызарга)

Гаризада күрсәтелгән документлар һәм белешмәләр дөрес.

Әлеге гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________

| | |
|---|---|
| Элемтә өчен телефоны | |

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен түбәндәгечә бирүегез турында үтенәм:

җибәрергә ____________________________________________________________;

(күрсәтелә: кәгазь чыганактагы электрон документ нөсхәсе рәвешендә; Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетка);

- Министрлыкта турыдан-туры тапшырырга ____________________________________
_______________________________________________________________________________.

(күрсәтелә: кәгазь чыганактагы документ формасында, электрон документ яки кәгазь чыганактагы электрон документ нөсхәсендә)

Мөрәҗәгать итүченең (вәкаләтле затның) ФИА, вазыйфасы һәм имзасы (мөһере (булган очракта))

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Үрнәк

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар ____________________________

Түбәндәгенең мөрәҗәгать итүенә бәйле рәвештә ________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

гариза №_____ _____ елның ____._____.________, ________________________________

_____________________________________________________________________________

түбәндәгеләр нигезендә: ______________________________________________________

_____________________________________________________________________________

тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде, чөнки:

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________.

Җитәкче________________________________/______________________/
(имза) (тулы имза)

Башкаручы
(ФИА)
______________________________
(башкаручының элемтә белешмәләре)

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Киңәш итеlә торган рәвеше

Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрына

_______________________________________________

кемнән: ____________________________________

(физик затлар, шәхси эшкуарлар өчен:

_______________________________________________

(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта);

урнашу урыны адресы:

___________________________________

(юридик затлар өчен: оешманың тулы һәм кыскартылган исеме:

_______________________________________________

оештыру-хокукый формасын күрсәтеп)

ИНН, ОГРН белешмәләре_________________________

урнашкан урыны: ________________________________

элемтә телефоны ________________________________

юридик зат адресы________________________________

_______________________________________________

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм

_____________________________________________________________________________________

(дәүләт хезмәте атамасы)

Язылган:_________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар: ______________________________________________

_____________________________________________________________________________________

Техник хатаны төзәтүегез һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегез турында үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1. ________________________________________________________________________
2. ________________________________________________________________________
3. ________________________________________________________________________

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карар хакында:

e-mail:_______________________________________ адресына электрон документ рәвешендә;

_____________________________________________________________________________;

_________________________________________________________________ адресы буенча кәгазьдәге документның таныкланган күчермәсе рәвешендә почта аша җибәрүне сорыйм.

____________;

- Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетка.

_______________________ _____ (__________________________)

(дата) (имза) (тулы имза)

Башкаручы (Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) тулысынча).

(Элемтә өчен телефон, E-mail)

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Дәүләт хезмәтен күрсәтү һәм аның үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 267-68-01 | eco@tatar.ru. |
| Министр урынбасары | 267-68-60 | Ilnur.Gubaydullin@tatar.ru |
| Минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе җитәкчесе | 267-68-95 | Aleksey.Chinarev@tatar.ru |
| Каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесе | 267-68-97 | Svetlana.Shutnikova@tatar.ru |
| Эшчәнлек башкару бүлеге җитәкчесе | 267-68-04 | eco@tatar.ru. |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Җир асты биләмәләреннән, табигать ресурсларынан файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге җитәкчесе | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar.ru |